| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** | | **СОВЕТ КАЗКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |
| 423761, Кәзкәй авылы, Беренче май ур., 2а йорт | | 423761, село Казкеево, ул. Первомайская, д. 2а |

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

17 сентябрь 2019 ел № 21

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Кәзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итәргә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлек халкының гомуми саныннан 30 проценттан да артмый һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру: Кәзкәй авылы зиратын коймалау, Тыннамас авылы зиратын коймалау;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: Кәзкәй авылының Колхоз, Үзәк урамнарына,

Тыңламас авылының Октябрь, Фазлыев Дәхлул урамнарына ташлы ком салу һәм грейдер белән тигезләү;

- Кәзкәй һәм Тыннамас авылларын су белән тәэмин итү;

- авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү эшләре: Кәзкәй авылының Колхоз, Үзәк, Беренче Май урамнары, Тыннамас авылының Октябрь, Фазлыев Дәхлүл урамнары урам яктырткычларын карап тоту; ял паркы территориясен төзекләндерү; җәяүлеләр сукмаклары урнаштыру;

-халык күплəп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны Кәзкәй авыл җирлеге бинасы Беренче Май урамы, 2а йорты, Кәзкәй мәдәният йорты бинасы Беренче май урамы, 1а йорты, Тыннамас авылы мәдәният йорты бинасы, Октябрь урамы, 72б адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.М.Хөрмәев